**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлегенең Глазово торак пунктында гражданнар җыены карары**

2024 елның 23 ноябре № 3

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлегенең Глазово торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (29.11.2023 №1532 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Глазово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, 2024 елның 23 ноябрендә узган «Сез Лениногорск муниципаль районы Глазовоавыл җирлегенең Глазоваторак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан тыш, 2025 елда 600 (Алты йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

1) тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Глазово авылында урам яктыртуына техник хезмәт күрсәтү);
2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Глазово авылында түбәндәге урамнар буенча юлларны кардан чистарту: Дала, Совет, Елга аръягы, Ленин, Тау асты урамнары);
3) традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар кору, төзекләндерү (Глазово авылындагы зират коймасын буяу);
4) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Глазово авылында Ленин урамында янгын гидранты урнаштыру)

соравы буенча узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 42 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 25 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 25 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлегенең Глазово торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлегенең Глазово торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Сез Лениногорск муниципаль районы Глазовоавыл җирлегенең Глазовоторак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан тыш, 2025 елда 600 (Алты йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

1) тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Глазово авылында урам яктыртуына техник хезмәт күрсәтү);

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Глазово авылында түбәндәге урамнар буенча юлларны кардан чистарту: Дала, Совет, Елга аръягы, Ленин, Тау асты урамнары);

3) традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар кору, төзекләндерү (Глазово авылындагы зират коймасын буяу);

4) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Глазово авылында Ленин урамында янгын гидранты урнаштыру) соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң ун көн эчендә түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Үрнәк-Күмәк ав., Мәктәп ур., 3а й., Глазово ав., Заречная ур., 13 й., Петропавловка ав., Горький ур., 19а й., Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районының
Глазово авыл җирлеге башлыгы Н.К.Карабаева